Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

12 октябрь, 2022 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кәвәл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 32 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән) Кәвәл авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Кәвәл авыл җирлеге Кәвәл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

Халык җыенын ике этапта үткәрергә:

- халык җыенының беренче этабы 2022 елның 28 октябрендә 09 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 18А йорт адресы буенча урнашкан ИП Саликеева кибет бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамы, Яшел урамы, Пионер урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- халык җыенының икенче этабы 2021 елның 3 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 18А йорт адресы буенча урнашкан ИП Саликеева кибет бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Киров урамы, Яңа урамы, Мәктәп урамы, Үзәк урамы, Тукай урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2023 елда Кәвәл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларны һәм мәктәп укучыларын, махсус хәрби

операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кәвәл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы В.И. Назарова